КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1171

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы; 2019 ел, 3 апрель, 262 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче; 2021 ел, 2 март, 110 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Баш ветеринария идарәсе) ветеринария өлкәсендә дәүләт сәясәтен (хайваннарның йогышлы һәм башка авыруларын (агросәнәгать комплексы (ветеринарияне кертеп) өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннанраслана торган исемлек буенча) ветеринария профилактикалавын оештыру, хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге, Татарстан

Республикасында ветеринария эше белән идарә итү мәсьәләләрен кертеп) (алга таба – башка авырулар) тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора.»;

1.3 пунктта «һәм учреждениеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның өченче абзацында «дәүләт күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) (01.06.12*).»;

3.3 пунктта:

3.3.24 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.24. Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

3.3.25 пунктчада «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге» сүзләрен «хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.27 пунктчада «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.31 пунктчада «контроле һәм күзәтчелеге» сүзләрен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм ветеринария белән нәтиҗәле идарә итүне гамәлгә ашырырга;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин